ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская, д.12 ,
423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы,
12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-22-21, факс:4-22-21, e-mail: Skar.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№1 29 январь 2025 года

2025 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Иске Каразирек авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 196 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2025 елның 1 февраленнән 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 26 гыйнварындагы «2024 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»гы 2 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның “29”январендагы 1санлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 3663, 93 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1119,90 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4381,54 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның “29”январендагы 1санлы карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 850,38 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны биреп тору һәм китерү | 2813,70 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 1119,92 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4381,37 |
| Барлыгы | 9165,37 |